КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ
ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ ҺӘМ ТАРИХЫ ФАКУЛЬТЕТЫ
Гамәли лингвитистика  һәм тәрҗемәчелек кафедрасы

# Татар теле

*(Гомуми мәгълүмат, күнегүләр, контроль тестлар)*

**Казан**
**2011**

Татар филологиясе һәм тарихы факультетының укыту-методик советы
(26 май, 2011 ел, 16 нче номерлы беркетмә)

Гамәли лингвистика һәм тәрҗемәчелек кафедрасы
(19 май, 2011 ел, 15 нче номерлы беркетмә)
карары белән басыла

Төзүче:
**Ф.Р. Сибгаева**, филология фәннәре кандидаты, өлкән укытучы

Фәнни мөхәррир:
**Ә.Ш. Юсупова**, филология фәннәре докторы, профессор

Рецензентлар:
1. **Ф.М. Хисамова**, филология фәннәре докторы, профессор
2. **Э.Н. Динмөхәммәтова**, филология фәннәре кандидаты, доцент

Сибгаева Ф.Р. Татар теле *(гомуми мәгълүмат, күнегүләр, контроль тестлар).* Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы. – Казан: Вестфалика, 2011. – 44 б.

Кулланмада тел белеменең төрле тармакларына караган гомум-теоретик һәм гамәли материалны үзләштерү өчен тәкъдим ителә. Кулланмада, белем күнекмәләрен ныгыту, белем дәрәҗәсен тикшерү өчен, лексик-грамматик, биремнәр һәм тестлар бирелә. Хезмәт югары уку йортларының татар филологиясе һәм тарихы, журналистика факультетларында белем алучы студентларга адреслана.

**Эчтәлек**

Кереш......................................................................................4
Фонетика ..................................................................................5
Лексика ....................................................................................9
Сүз   ясалышы .........................................................................12
Морфология ............................................................................14
Синтаксис. Пунктуация ..........................................................19
Лингвистик анализ үрнәкләре ...............................................25
Контроль тестлар ...................................................................28
Зачет өчен якынча сораулык .................................................37
Төп әдәбият исемлеге ............................................................39
Өстәмә әдәбият исемлеге .......................................................39

## Кереш

“Татар теле” курсы өйрәнелә торган лингвистик фәннәр арасында үзенчәлекле урын алып тора. Ул телнең гамәли ягын карый. Курс дәвамында татар телен гамәлдә куллануга басым ясала..

Курсның төп эчтәлеге татар тел белеменең барлык тармакларын да карап, аларга бәйле күнегүләр, иҗади биремнәр башкару, гамәлдә кулланырга өйрәтү. Курс шулай ук студентларны лингвистик терминология белән эш итәргә өйрәтүне, лингвистик анализ төрләрен, методларны карауны күз уңында тота. Өйрәнелә торган нәзари материалны ныгыту, студентларның лингвистик фикерләү сәләтен, тел фактларын анализлау осталыкларын үстерү максатыннан гамәли дәресләр дә үткәрү каралган.

“Татар теле” курсы укыту кулланмасы тарих, татар филологиясе һәм тарихы, журналистика һәм социология факультетларында белем алучы студентлар өчен төзелде. Укыту кулланмасында кыскача лекция материаллары, күнегүләр, тестлар, күнегүләр, белемнәрне тикшерү өчен тест, лингвистик анализ үрнәкләре, төп һәм кулланылган әдәбият исемлеге тәкъдим ителә. Кулланмада гамәли материал карала, аерым сорауларга бәйле өстәмә мәгълүмат бирелә.

# Ф О Н Е Т И К А

Фонетика турында төшенчә. Сөйләм авазлары. Сөйләм органнары. Сузык һәм тартык авазлар, алар арасындагы аерма.

Сузык авазларның саны һәм составы. Рәт гармониясе, ирен гармониясе /Сингармонизм законы/. Сузыкларның кыскаруы /редукция/.

Дифтонглар. Татар телендә аларның үзенчәлеге һәм язуда бирелеше.

Тартык авазлар. Анарның саны һәм составы. Тартык авазларны төркемләү. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Сөйләмдә тартыкларның охшашлануы.

Интонация. Иҗек. Татар телендә иҗек калыплары. Басым. Татар телендә сүз басымының урыны. Басым соңгы иҗеккә төшми торган очраклар.

Орфоэпия һәм орфография. Татар телендә орфографик принциплар. Авазларны язуда күрсәтү. Алфавит. “ъ” һәм “ь” хәрефләренең дөрес язылышы.

Графика. Татар халкында язу тарихы.

## Күнегүләр. Биремнәр
## Фонетика. Орфография

**1. Күпнокталар урынына “Ъ” яисә “Ь” хәрефләрен куеп языгыз.**

Тәк…дим, мәнфәгат…, иг…тибар, роял…, дөн…я, дәр…я, сәгат…, шигыр…, сәнгат…, бер…юлы, тугыз…еллык, күп…еллык, көн…як, пул…с, мөрәҗәгат…, гам..., бәгыр…, кәгаз…, тәнкыйт…, мәшгул…, һәр…яклап, асфал…т, мик…дар, шиг…ри, шагыйр…, ик…тисад, мәг…лүм, Дөб…яз, Ак…егет, җәмгыят…, дик…кат…, дәг…ва, гыйл…ми, с…езд, йөз…яшәр, мәг…рифәтче, мәкал…, мәшәкат..., җөр…әт итү, тәг…бир, тигез....яклы, табигат…, мәг…кул…, ниһаят.., волост…, бинокл…, стил…, шәфәк…., гаят…, фәкат..., Кор…ән, мәс…әлә, мәс…үл, Ях…я, п…еса, мәшрик..., бәг...зе, фәкат..., лөгат..., юн...сез, вәзгыят..., монафик..., кар...ера, ад...ютант, об...ект, суб...ект, тәкат..., шәл...яулык, таш...язма, мәг...шука, сөал..., яш...тәш, кул...яулык, кул...югыч, ук...яфрак, төн...як, буар...елан, бер...юлы.

**2. Күпнокталар урынына Х яисә Һ хәрефләрен куеп языгыз. Сүзләрнең мәгънәләрен аңлатыгыз.**

Мө…әррир, мәш…үр, …өрмәт, мә…абәт, …алык, ә…әмият, …өкем, шә…си, …уҗалык, а…ыргы, җә…әннәм, бә…әс, …әлак, и…тирам, а…әң, и…тыяҗ, шө…рәт, и…тимал, ма…сус, и…ата, зәм...әрир, ми…нәт, җи…аз, мәр…әмәт, мә…рүм, мә…әббәт, да…и, мә…шәр, …әйкәл, нөс…ә, оҗма…, ру…и, рә…имле, җөм…үрият, …акимият, фати...а, …аләт, ….арап, пә...леван, …асият, …икмәт, җә…әт, …исапчы, …өнәр, …ава, …аман, …әвәс, …озурлык, гөна..., ...авалану, дә…шәт, зин…ар, мо....таҗлык, зи…ен, зә…әр, ил…ам, …осусый, …орафат, …әбәрдар, …әвеф, …ичшиксез, …ыянәт, …әйран, …әрәкәт, ә...ел, …әсрәт, иҗти…ад, ка…арман, шөб…ә, җәү…әр, …әвәскәр, …әлакәт, …өҗүм, …осусан, оҗма…, си…әт, фә…ем, солы…, бәр…ет, …өрлек, пө..тә, исла...., мә...кәмә, ...әрабә, тәсби..., я...үди, ...илаф, кә...вә, сә...рә, мөҗа...ид, ...өрәсән, али...ә, мә...әллә, ...әндәсә, ...арәм, мө...аҗир, шөб....әләнү, ба...адир, ...ирыс, ша...задә, имти...ан, мәз...әб, сә...әр.

**3. Күпнокталар урынына Ж яисә Җ хәрефләрен куеп языгыз.**

Ма…ара, …епшек, вө…дан, …әлләргә, …ирәбә, …илет, …авап, …айдак, …айлашу, …ентекле, …ан, ха…, …әймә, ху…алык, …әһәт, …омга, …итәкче, …ыелу, …итди, …имерек, ….илем, кал…а, ….илкендерү, мә...бүр, ...ор, ...иләк, ы....гыру, вы....ылдау, ...итештерү, бо...ыр, га....әп, га....из, ....аһил, ....айланма, әл....е-мәл....е, ....ыерчык, .....ән....ал, ....ыйнак, һө....үм, рән....ү, о...мах, мор...., мор...а, мог....иза, карал.....ым, ү....әт, зөбәр....әт, ...иткерү, ал....ыту, ба...а, ...гут, ....ираф, ....окей, ....әл, мохта...., а...гыру, а....даһа, гө....елдәү, гө... килү, ....улик, ...уылдау, мә....нүн, кәл...емә, мы....гу, ....етон, ...онглер, ....ария, шә....әрә, ....анвар, хан...а, ....әдвәл, ....әдитчелек, дәрә...ә, ...әлт, ....еназа, ....исем, һи...ри, пәрән....ә, имид...., та...., са....ин, картдри..., кин...ал.

**4. Күпнокталар урынына тиешле хәрефләрне куеп языгыз.**

Кояш әллә нинди: инде сезне ...ылыта-...ылыта

аптырадым, арыдым дигән кеби, зәг...ф... кенә нурларыны чәчеп, тирә-ягыны ...ылыта, йомшак кына итеп яктылыгыны тутыра. Ул инде, ...әйге көн кеби, башларыңнан миләреңне эретеп чыгарырлык булып мәр...әмәтсез кыланмый. Аның ...әзер шәфк...т...ле нуры мәр...әмәт...ле. Ул киң Кабан күле өстендә дә, элгәреге кеби, ялтыр-йолтыр иттереп, яш... батырның кылычыны уйнатуы кеби кыланмый. Аны да кызганган кеби, аны да киләчәк суыкларга чыдарга димләгән кеби, үзенең йомшак ...ылысы берлә кочаклап, елмая-елмая гына бә...илләшә, саубуллаша. Ул ...әзер, элгәреге кеби, агачларның яфракларында, алар матурлыгына көнләп, кыздырырга теләми. Ул аларның соры йөзләренә көлемсерәп карый, аларга дуслык ...аләмәте күрсәтә. ...ава да бүген тып-тын. Әллә ник...дәр очып йөри торган үрмәкүч ...епләре, ...илдән дә, эсседән дә курыкмаенча, әллә кая таба китәләр. Иске коймалар янындагы кызыл-кызыл «мар...алар» да бик ...аваланып кына кояшның ...ылысында рә...әтләнәләр, туйлар ясыйлар. Бөтен ...ава әллә нинди алма, кавын, карбыз, кабак исләре берлә тулган. Өйләрдән әллә нинди туклык исе чыга.

Кешеләрнең йөзләрендә эшлеклелек балкый (Г. Исхакый).

**5. Сингармонизм законына буйсынган һәм буйсынмыйча килгән сүзләрне аерып төркемләгез.**

Күңелдәгесен, ателье, бертоташтан, балаларыбыздан, көндәлектә, директор, өстәлгә, көлсу, килделәр, барасыңмыни, әйткәләштергәләдем, кузаллау, офис, дусларыбызга, ихата, хөрмәтле.

**6. Бирелгән сүзләрнең дөрес язылышын тикшерегез.**

Очырау, пычырату, әкерен, очырак, ихыласлылык, йомырка, йомыры, ачылу, йөгерек, килешү, аңышмастан, багыланыш, басылу, бөкере.

**7. Күпнокталар урынына тиешле хәрефләрне куеп языгыз.**

К...з килде… Урман ..ст...ннән й...г..р..п узган алтын б..л...т агачларның яфракларын сары т...скә манды. Усалрак җил

искәндә, алар күз яшьләре сыман җир ...ст...нә тамдылар. Куаклардагы чикләвекләр дә тәмам саргаеп җиргә коелдылар. Менә б...рк...нн... ешлык араларын к...мд...р утап чыккандай, урман куелыгы шәрәлеккә ал..ш..нды… Үз...н...ң сары саг...шлары, м...ң карг...шлары белән тулган к...з. Күкләр дә хәзер җәйге к...ннәрдәге к...б...к д...б...рдәп-күкрәп каты итеп яшь коеп еламый, ә тавыш-т...нс...з гына, саб...р карч...клар к...б...к кенә балав...з сыга. (Р.Сибат).

**8. Күпнокталар урынына В яисә У/Ү хәрефләрен куеп языгыз.**

Өстә…енә, сора…, дә…амлы, аның кара…ы, ба…ырсак, рә…еш, ә…ерелү, әү…әл, …атык, дә…ер, …әгъдәләш…, яңгыра…ык, җемелдә…ек, берка…ым, ә…әләү, җәд....әл, са....ыктыру, г....елдәү, гөрелдә....ек, пәрә....ез, боз....аткыч, к...әт, һә....әскәр, һа....алану, кәр....ан, к...алау, та..чык, тарла...ык, пәһле...ан, пәхлә....ә, ә....әрә килү, ә....еш-тә....еш, әзмә....ер, ә....мәкләү, ә...лия, ...әс...әсә, дерелдә...ек, елтыра...ык, ирдә...кә, ка...ем, ка...ыштыру.

**9. Сүзләрнең басымын билгеләгез.**

Кайдадыр, ярамый, төлкедәй, бүгенгедәй, эшләмәскә, әйтегез, бәхетлемен, килгәнсең, күрермен, безнеңчә, дусларча, беркем, укымасын, чагыштыр, үскәнче, укыткандыр, беләләр, кайттыгызмы, телиләр, һәркем, әллә нинди, бернәрсә, һичкайда, бердәнбер.

**10. Сүзлек диктанты языгыз.**

Тәкъдим, зинһар, хисап, вәгъдә, мәнфәгать, сәгать, катгый, куәт, әһәмият, мәгълүм, могҗиза, гомуми, мөгаен, мәрхәмәт, микъдар, нәзакәт, гадәти, мәшәкать, күпьеллык, шәфкать, нәкыш, пакълек, рәхим-шәфкать, кагыйдә, мәшгуль, вазифа, мөгаллим, мөнәсәбәт, шартнамә, хөрмәт, нәшрият, әдәбият, имтихан, җәмәгать, сәламәтлек, кадер, дөнья, төньяк, бәхәс, гамәл, хәзер, харәм, боерык, беркем, васыятьнамә, басмаханә, үзкыйммәт, хуҗалык, кардәш, кодрәтле, тәэмин итү, мәсьәлә, һичбер, газиз, гомер, ниһаять, гаять, мөһим, тарих, кадер, җәмгыять, горур, ягъни, гаделлек, гасыр, һәркем, канәгать,

кульязма, гаеп, ризык, мәдәният, иҗтимагый, вәгазь, һөнәр, нигъмәт, игълан, гариза, хокук, мөстәкыйль, ихтыяҗ, гаҗиз, тормыш-көнкүреш, гыйлем, гомумән, каләм, галәм, мөлкәт, вәкаләт, мәгариф.

## Л Е К С И К А

Лексика телнең сүзлек составы турында төшенчә. Сүзнең мәгънәсе.

Килеп чыгышы буенча татар теленең сүзлек составы: төрки-татар сүзләре, гарәп-фарсы, рус һәм европа теленнән кергән алынмалар.

Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр. Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре. Омонимнар, аларның төрләре. Антонимнар. Синонимнар.

Кулланылыш сферасы ягыннан татар теленең сүзлек составы: тарихи сүзләр, архаизмнар һәм неологизмнар. Гомумкулланылыштагы сүзләр. Һөнәрчелек лексикасы. Диалекталь сүзләр.

Татар телендә фразеологик әйтелмәләр.

Лексикография. Сүзлекләрнең төрләре: аңлатмалы һәм телара сүзлекләр.

Ономастика. Аның тармаклары.

### Күнегүләр. Биремнәр

**1. Сүзләрнең синонимик парларын туры китереп языгыз. Аларның мәгънә төсмерләрен аңлатыгыз.**

Алыш-биреш, исән, сәламәт, сату (сәүдә), чират, аксак, нечкә, никадәр, ашлык, олы, кызык, рәсем, күпме, нәзек, чатан, нәүбәт, сурәт, мәзәк.

**2. Сүзләрнең антонимнарын табыгыз һәм аларның кайсы сүз төркемнәренә каравын әйтегез.**

Җыйнак –; җиңел –; үлем –; өз –; өзү –; әшәке –; әкрен –; яңа –; яшьлек –; якты –; яраклы –; якын –; юк –; югалту –; юан –; юаш –; эчке –; эссе –; эволюция –; шатлык –; чыгу –; чишү –; көн –; кыйммәт –; чиста –; чи –; хәерче –; хуплау –; фәкыйрь –;

файда –; уң –; уңайлы –; тук –; тыгыз –; туры –; тозлы –; чиста –; чи –; хәерче –; хуплау –; фәкыйрь –; файда –; сүтү –; симез -; сүрән –; сөенеч –; сорау.

**3. Бирелгән фразеологизмнарның мәгънәләрен аңлатыгыз, синонимнарын табыгыз.**

Кызыл әтәч җибәр; авырткан җиргә кагылу; кеше кубызына бию; кесәгә сугу; борын төбендә генә; бусагасын төшерү; дүрт куллап; күзгә бәрелеп тору; беткән баш беткән; телсез калу; авызга сулар килү; көймәсе комга терәлү; юлыңа ак җәймә; бәхет йөзлеге белән туу; озын сүзнең кыскасы; күңелдә төер калу; санга сукмау; төшеп калганнардан түгел; уртак тел табу; колакларны торгызу; тел очында гына тору.

**4. Бирелгән сүзләрнең синонимнарын табыгыз, һәрберсен антонимы белән алыштырыгыз.**

***Үрнәк:*** *бәйсез* (бәйле) – хөр (тоткын), азат (бәйле), ирекле (ирексез), мөстәкыйль (бәйле).

Яшь, керү, иртән, юмарт, ихлас.

**5. Тексттагы сүзләрнең килеп чыгышлары ягыннан кайсы телгә нисбәтле булуларын ачыклагыз.**

1999 елда татар сынлы сәнгатенең аксакалы Бакый Урманче музее ачыла. Ул Щапов урамындагы 20 нче йортта урнашкан.

Өч катлы музей йортында Бакый Урманченың сынлы сәнгатьнең барлык өлкәләрендә иҗат иткән эшләре урын алган.

Бакый ага – татарның Кол Гали, Мәрҗани, Насыйри, Тукай, Дәрдмәнд, Җәлил кебек шәхесләренең образларын һәм үзенең замандашларының йөздән артык график портретларын, скульптуралар, меңнәрчә этюд, пейзаж, шамаилләр эшләгән автор (И.Минһаҗевадан).

**6. Бирелгән сүзләрнең кайсы төркемгә нисбәтле булуын ачыклап языгыз.**

*Тарихи сүзләр:*

*Архаизмнар:*

*Неологизмнар:*

*Диалекталь сүзләр*:

Күмхуҗ, становчы, сәхабә, метагалактика, санак, плеер, вәзир, дәресханә, сыйхәт, (шифа) эстәү, вә, фалиҗ, кәшәтаяк, дастук, тал пипие, бәпчү, болгавыр, сканер, интерфлот, импичмент.

**7. Гарәп-фарсы алынмалары нигезендә ясалган фигыльләрнең мәгънәләрен аңлатыгыз, аларны сүзтезмәләрдә кулланыгыз. Сүзләрнең дөрес язылышын истә калдырыгыз.**

1) Икърар итү, шөкер итү, тәэсир итү, вәгъдә итү, шәфкать итү, тәнкыйть итү, шикаять итү, иҗтиһат итү, хыянәт итү, мәслихәт итү, гафил итү, тәкъдим итү, тәэмин итү.

2) Мәрхүм булу, балигъ булу, даими булу, мәгълүм булу, һәлак булу, пәйда булу, канәгать булу, гашыйк булу, фәкыйрь булу, разый булу.

3) Тәүбә кылу, хөрмәт кылу, гөнаһ кылу, шөкер кылу, карар кылу, сәҗдә кылу, риваять кылу.

**8. Гарәп-фарсы телләреннән кергән сүзләрнең дөрес язылышын истә калдырыгыз. Аңлатмалы сүзлектән файдаланып, сүзләрнең мәгънәләрен аңлатыгыз.**

Мөхәррир, мәхәббәт, тәкәббер, ләззәт, җәллад, тәкәллеф, тәэссорат, маддә, тәвәккәл, җәһәннәм, кыйммәт, мәхәллә, тәхәллүс, валлаһи, бәллүр, бәддога, сөннәт, милләт, мәккә, мөкәммәл, иттифак, рәссам, вәссәлам, гыйззәтле, дәҗҗал, кыйсса, мөдәррис, мөкаддәс, билләһи.

**9. Рус-европа теленнән кергән сүзләрнең басымын дөрес куеп укыгыз, мәгънәләрен аңлатыгыз. Дөрес язылышын истә калдырыгыз.**

1) Авиапочта, автобаза, акула, анализ, антоним, аппликация, аптека, арена, архитектор, агрономия, бантик, барометр, консул, контур, корпус, космос, кризис, кухня, кушетка, ландыш, лексика, лекция, линия, лирика, лозунг, люцерна, марка, масса, мастер, милиция, бронза, буйвол, бухгалтер, ванна, варенье, велосипед, вентилятор, гербарий, глобус, минус, митинг, океан, орфография, палуба, Польша,

папка, паспорт, пауза, пенсия,  пирамида, пластинка, платформа, полюс.

2) Прожектор, пружина, республика, санаторий, сессия, госпиталь, груша, дамба, делегация, диагноз, диаметр, дивизия, дизель, зона, инкубатор, кабина, слесарь, смена, снайпер, сода, станция, староста, стачка, сумма, схема, табель, таблетка, теория, теплица, термос, терасса, титул, тополь, троллейбус, коллиграфия, камера, каска, квитанция, керамика, клиника, кнопка, кодекс, команда, комедия, конкурс, фигура, флейта, фундамент, химия, центнер, цитата, циркуль, шахта, экскаватор, экскурсия, элеватор, электрик.

**10. Күпнокталар урынына тиешле хәрефләрне куеп, алынма сүзләрне языгыз.**

Проз...ик, п...рп...нд...куляр, пр....мьера, пр...т...нзия, т...ор....тик, брош....ра, бр...нет, в....рн....саж, к....лейд....скоп, п...н....рама, с....м...нтика, хр....ст...матия, ст....п...ндия, с...м...нар, д....л...катес, пр...з...д...нт, эксп....р...м....нт, апр....б...ция, к....мп...нент, фо...е, в...н...грет, ж...тон, лан...шафт, н...т...риус, р...клама, ц...м...нт, эстаф....та, т...бр, ди...та, мод...льер, стату...тка, к...тт...дж, паци...нт, кли...нт, ...нтузиазм, г...потеза, аг...нтство.

## С Ү З   Я С А Л Ы Ш Ы

Сүзнең мәгънәле кисәкләре. Тамыр һәм кушымча.

Ясагыч һәм мөнәсәбәт белдерүче (модальлек белдерүче һәм бәйләгеч) кушымчалар. Кушымчаларның вариантлары.

Сүзнең нигезе. Сүз ясалышы ысуллары. Ясалышы ягыннан сүз төрләре. Ясалма һәм кушма сүзләр. Кушма сүзләрнең саф кушма, парлы һәм тезмә төрләре. Кыскартылма сүзләр.

Сүзләрнең мәгънәсе үзгәрү. Сүзләрне бер сүз төркеменнән икенчесенә күчерү (конверсия).

## Күнегәләр. Биремнәр

**1. Бирелгән сүзләргә тиешле урыннарда -лык/-лылык (-лек/-лелек) кушымчаларын ялгап, яңа сүзләр ясагыз.**

Ак..., кеше..., туган......, әдәп.., кирәк..., изге...., сәламәт..., шат..., гадел..., гаеп..., даһи...., нәзакәт...., сәламәт...., ун..., дәһшәт..., бердәм..., билге..., туры..., вәкарь..., савап...., канәгать..., бай........, еш....., очрак...., гомер......, аң..., зарур....., матур.....

**2. Җәяләрне ачып, кушма сүзләрне дөрес итеп языгыз. Сүзләрнең дөрес язылышын аңлатып, нәтиҗә ясагыз.**

Авиа (модель), авиа (десант), авто (машина), авто (граф), авто (биография), авто (төягеч), агро (химия), агро (техника), аэро (дром), аэро (вокзал), аэро (план), аэро (порт), аэро (чана), био (графия), био (станция), био (сфера), био (физика), гидро (терапия), гидро (энергия), гидро (техника), гидро (логия), гидро (инкубатор), гидро (метеорология), зоо (парк), зоо (ветеринар), зоо (техник), зоо (логия), кино (студия), кино (тасма), кино (прокат), кино (картина), кино (актриса), кино (кадр), микро (ашлама), микро (биология), микро (космос), микро (климат), мото (спорт), мото (каток), радио (постановка), радио (репортаж), радио (трансляция), радио (физика), радио (сөюче), радио (телефон), радио (телеграмма), теле (механика), теле (монтаж), теле (хроника), теле (күргәзмә), теле (граф), теле (аппаратура), фото (студия), фото (күргәзмә), фото (рәсем).

**3. Җәяләрне ачып, кушма, парлы, тезмә сүзләрне дөрес итеп языгыз.**

Ярым (утрау), ярым (бoҗра), ярым (йорты), ярым (шар), ярым (үткәргеч), ярты (килограмм), ярты (еллык), ярты (гасыр), ярты (лаш), ярты (йорты), ярты (акыл), ярты (юлда), ярты (сәгать), әйләнә (тирә), ярым (әйләнә), әйлән (бәйлән).

**4. Җәяләрне ачып, кушма, парлы сүзләрне дөрес итеп языгыз.**

Төн (боек), төн (як), төн (буе), өч (почмак), өч (буын), өч (аяк), өч (томлык), өч (яклы), өч (көнлек), өч (айлык), өченче (көн), туры (сүзле), туры (почмаклык), көн (батыш), гала (концерт), халык (ара), ярым (утрау), премьер (министр), пед (институт), радио (тапшыру), көн (як), хатын (кыз), су (саклагыч), гореф (гадәт), көн (озын), бер (юлы), авто (узыш), авто (үз) (бушаткыч), радио (элемтә), аяк (үрә), аяк (өсте), милләт (ара), үз (йөрешле), һич (сүзсез), биш (урынлы), биш (еллык).

**5. Парлы сүзләрнең басымнарын дөрес куеп укыгыз. Парлы сүзләрнең нинди мәгънәле сүзләрдән ясалуын аңлатыгыз. Бирелгән сүзләрне кулланып, җөмләләр төзеп языгыз.**

Кадер-хөрмәт, шау-шу, хәер-сәдака, ким-хур, ару-талу, әйләнү-(бәйләнү) тулгану, ярым-ярты, рәхим-шәфкать, шик-шөбһә, абына-сөртенә, чит-ят, бата-чума.

## МОРФОЛОГИЯ

Сүз төркемнәре турында төшенчә. Татар телендә сүзләрне төркемнәргә бүлү.

Мөстәкыйль сүз төркемнәре /исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль, рәвеш, аваз ияртемнәре/. Бәйләгечләр /теркәгеч, бәйлек/. Модаль сүз төркемнәре /хәбәрлек сүзләр, кисәкчә, ымлык/. Ымлыклар һәм аваз ияртемнәре.

Грамматик мәгънә һәм грамматик чара.

### ИСЕМ

Исемнең мәгънәсе һәм грамматик билгеләре. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Исемнең сан, килеш, тартым белән төрләнеше. Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Исем ясалышы.

Фамилия ясаучы кушымчалар.

### СЫЙФАТ

Сыйфатның грамматик билгеләре. Асыл һәм нисби сыйфатлар. Сыйфат һәм сыйфатланмыш.

Сыйфат дәрәҗәләре /гади, чагыштыру, артыклык, кимлек/. Сыйфатларның исемләшүе. Сыйфат ясальшы.

## САН

Сан турында гомуми төшенчә. Сан һәм саналмыш. Сан төркемчәләре: төп сан, тәртип, бүлем, чама,  җыю саннары.

Санның ясалышы. Саннарның дөрес язылышы.

## АЛМАШЛЫК

Нинди сүз төркеме алмашлык дип атала? Алмашлыкның төркемчәләре.

Алмашлыкның төзелеше һәм дөрес язылышы.

## ФИГЫЛЬ

Фигыльгә гомуми характеристика. Аның барлык-юклык, зат-сан, заман белән төрләнеше.  Фигыль төркемчәләре. Фигыль юнәлешләре: төп, төшем, кайтым, йөкләтү, уртаклык. Фигыльдә дәрәҗә белдерү.

Затланышлы фигыль формалары /хикәя, боерык, шарт, теләк/ һәм затланышсыз фигыльләр /сыйфат фигыль, хәл фигыль, исем фигыль, инфинитив/.

Хикәя фигыльнең заман формалары.

Сыйфат фигыльнең заман формалары. Сыйфатка һәм фигыльгә хас үзенчәлекләре.

Исем фигыльдә исемгә һәм фигыльгә хас үзенчәлекләр.

Хәл фигыльнең төрләре һәм кулланылыш үзенчәлекләре.

Ярдәмче фигыльләр. Фигыльләрнең ясалышы.

## РӘВЕШ

Рәвеш турында төшенчә. Аның лексик-семантик, морфологик һәм синтаксик билгеләре.

Рәвеш төркемчәләре. Билге һәм хәл рәвешләре.

Рәвешнең ясалышы.

## АВАЗ ИЯРТЕМНӘРЕ

Мөстәкыйль сүз төркеме буларак аваз ияртемнәре. Аларның үзенчәлеге.

## ТЕРКӘГЕЧ ҺӘМ ТЕРКӘГЕЧ СҮЗЛӘР

Теркәгечләр, аларның функциясе. Теркәгечләрнең төркемчәләре.

Теркәгеч сүзләр. Аларның үзенчәлеге.

Бәйлек һәм бәйлек сүзләр. Үзләреннән алда килгән сүзләрнең нинди килештә булуын таләп итүдән чыгып, бәйлекләрнең төркемчәләре.

## МОДАЛЬ СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕ

Кисәкчәләр һәм аларның төркемчәләре. Кисәкчәләрнең дөрес язылышы.

Хәбәрлек сүзләр турында төшенчә.

Ымлык һәм аның төрләре.

## Күнегүләр. Биремнәр

**1. Исемнәрне сан, килеш, тартым кушымчалары белән төрләндерегез. Бирелгән сүзләрне кулланып, 10 җөмлә төзеп языгыз.**

1) Модель, медаль, июль, гастроль, рояль, автомобиль, патруль, фестиваль, акварель, ансамбль, мораль, вексель, дуэль, бандероль, деталь, вермишель, коктейль, карамель.

2) Власть, волость, нефть, повесть, промышленность.

1) Ноябрь, декабрь, январь, лагерь, календарь, секретарь.

4) Банк, очерк, митинг, лозунг, маркетинг, киоск, бланк, парк.

5) Интеллигент, концерт, доцент, конкурент, парламент, документ, менеджмент, абонемент, темперамент.

6) Дирижер, диспансер, центнер, офицер, режиссер, диспетчер, тренер, лидер, мэр, тенор, шофер, актер.

7) Баһадир, Җиһангир, сувенир, анализ, грузин.

**2. Исемнәрне сан, килеш, тартым кушымчалары белән төрләндереп языгыз.**

Маскарад, йод, период, рекорд, съезд, аккорд, логопед, рейд, бильярд, фонд, метод, масштаб, монолог, диалог, каталог, айсберг, коттедж, колледж, манеж, престиж, пляж, монтаж, тираж, массаж; коралл, металл, балл, кросс, грамм, грипп, нарцисс, компромисс; какао, кресло, пальто, цунами, жюри, ателье, кафе.

**3. Тиешле хәрефләрне куеп, җөмләләрне күчереп языгыз.**

1) Тормыш һәм андагы конфликт(лар/ләр) авырлыгын үз иңнәреннән төшерергә, дуслар җилкәсенә күчерергә, аңлы рәвештә кызгандырырга тырышкан кеше көчсез

(Ә. Баян) 2) Садыйк абзый (хуҗаның исеме шулай иде) шәһәрдәге ниндидер бер учреждение(да/дә) эшли икән (А. Шамов). 3) Стенага элгән календарь(ның/нең) ертылмаган соңгы ун көне (М. Җәлил). 4) Варис алдына җәеп салган календар(ы/е)(ның/нең) бер битенә нәрсәдер язып куйды (М. Хәсәнов). 5) Тимербулатов көнен-төнен чаба, завод(лар/ләр)(да/дә), конструкторлыкбюролар(ы/е)(нда/ндә), предприниматель (лар/ләр)(да/дә) була (А. Расих). 6) Татар халкында әни белән ипи сүзе бергә йөри, аларның мәгънә кондиция(лары/ләре) бертигез (М. Мәһдиев). 7) Репетиция(лар/ләр) таңга кадәр сузыла, артистлар, уеннарын режиссер(га/гә) ошата алмыйча, манма тиргә баталар (Г. Бәширов). 8) Президент шәхес хокуклары һәм ирекләренең, республикабыз суверенитетының, Конституция(ны/не) һәм законнарны үтәүнең, шулай ук халыкара шартнамәләрнең гаранты булып исәпләнә.

**4. Тартым кушымчасы белән килгән исем фигыльләрне дөрес итеп языгыз.**

Уку...ы күңелле, гафу үтенү...ем, бурычны түләү...ең, шәл бәйләү...е, аларның сорау...лары, сезгә килү...ебез, агачка үрмәлә...ең, йомышны үтәү...ләре, сиңа әйтү...ем, дикторның сөйләү..е, безне сәламләү...егез, вакыйганы тасвирлау...ым, халыкның туплану...ы, халыкны туплау...ы.

**5. Исем фигыльләрне күрсәтелгән грамматик формаларга куеп языгыз. Төшеп калган хәрефләрне билгеләгез.**

Көзге авыл… Ишегалды — минем олы д....н....ям. Монда ....әммә җан иясе үз г....мендә… Көр сыерның м....грәп куй *(3 з., б. с., ис. ф.).* Тук казларның, утырган җиреннән генә түшен биетеп, борын эченнән генә гаң-гаң килеп г.....пләш *(3 з., к. с., ис. ф.).* Ю.....ш танаулы сарыкларның мекер-мекер печән уртла *(3 з., б. с., ис. ф.).* Г....нҗәлә койрыклы әтәчнең күрше тавыкларын койма ярыгыннан күзәтеп, баскан урынында тәк.....т.....сез тыпырда *(3 з., б. с., ис. ф.)…* Мендәр өстеннән уянып чыккан песинең ак тәпиләре белән салкын җиргә басарга теләмичә, баскыч биеклегеннән әлеге малларга — «кара

......алыкка» түбәнсетеп карап тор *(3 з., б. с., ис. ф.).* Әнә шулай ишегалды яши, оз....н кышка әзерләнә. Кышкы аклыкка күзне иямәштерер өчен, күктән к.....м...ш сыкы тузаны сирпелә. Нинди рәхәт, күкрәккә иркен к.....м...ш .....ава ургылып керә (М. Галиев.).

**6. Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатлар ничек язылалар? Җәяләрне ачып, сүзләрне аерым яки сызыкча аша языгыз.**

Чып (чын), чалт (аяз), түм (түгәрәк), чем (кара), шыр (тиле), дөм (караңгы), тома (сукыр), кап (караңгы), сап (сары), өр (яңа), җете ( кызыл), тип (тигез), чуп (чуар), зуп (зур), вак (вак), куе (яшел), сыек (зәңгәр), коңгыр (кара), аксыл (сары), иксез (чиксез), очсыз (кырыйсыз).

**7. Җөмләләрдә кулланылган сыйфатларның дөрес языльшын билгеләгез.**

1) Ачу хәтәр, ачудан гайбәт хәтәр ...рәк икән (Т. Галиуллин). 2) Сугыш бетеп, армиядән кайткач та, үз өенә кермәстән, туп (туры) Гөлсем апаларга кагылды (Г. Әпсәләмов). 3) Кар суы, чишмә суы кебек тәмле булмаса да, салкын, чиста була, керне ныг...рак агарта, чәчне әйбәт...рәк йомшарта иде (М. Маликова). 4) Үзеннән бер башка сәләтлерәк укучысын әзерли алмаган остазны үзеннән ун башка сәләтсез...рәк укучысы таптап китә (М. Галиев).

**8. Кирәкле кушымчаларны кулланып, бирелгән сүзләрдән ясалма сыйфатлар ясап языгыз.**

Акыл, бәхет, ташлама; физика, химия, педагогика, техника; объект, субъект, акционер, аудитор, менеджер, продюсер, фермер.

**9. Җөмләләрдәге фигыльләрне күрсәтелгән формаларга куеп языгыз. Дөрес языльшын аңлатыгыз.**

Бала уйна ….. *(билгеле кил. заман).* Ул бие…. *(билгеле кил. заман).* Бала борчы…. *(билгеле кил. заман).* Без бие.. *(хәз. заман).* Малай йөр….*(билгеле кил. заман).* Су кими…. *(билгеле кил. заман).* Кыз укы…. *(билгеле кил. заман).* Без ю….. *(теләк*

*фигыль).* Кояш байый…. *(билгеле кил. заман).* Пальто ки….. *(теләк фигыль).* Ул төя...... *(билгеле кил. заман).*

**10. Җөмләләрдә кулланылган алмашлыкларның дөрес язылышын билгеләгез.**

1) Хәят ***бер (ничә)*** минутлар шул хәлендә калганнан соң, хәтерендә кинәт ***бер (нәрсә)*** килеп төшкән кешенең ашыгычлыгы белән, тәрәзә яныннан китте дә ридикюленнән зур төргәк хат чыгарды (Ф. Әмирхан).

2) Хәтфә күзләр ***әллә (кая)***, еракка, югарыга киттеләр, аларга Хәятның йөрәгенең буе җитми башлады. Аларның нуры да хәзер инде Хәят өстенә түгел, ***әллә (кая)*** читкә чәчри иде (Ф. Әмирхан).

3) Бу — кәккүк! Кешеләрнең исләренә ***нинди (дер)*** бик мөһим нәрсәне төшерер өчен табигать тарафыннан яратылган күзгә күренмәс сәер кош! ...(Ә. Еники).

4) ***Әллә (кайчаннан) (бирле)*** эленеп тора инде сыңар бияләй өрәңге ботагында (Ф. Шәфигуллин).

5) Беренче карашка кар бик нык ята әле, ***бер(кайда) (да)*** чүмечләп-чиләкләп алырлык су күренми (М. Маликова).

## С И Н Т А К С И С. П У Н К Т У А Ц И Я

Синтаксис һәм өйрәнү предметы. Төп синтаксик берәмлекләр.

Җөмләдә сүзләр бәйләнеше: тезүле һәм ияртүле бәйләнеш. Тезүле бәйләнешне белдерүче чаралар. Ияртүле бәйләнешне белдерүче чаралар. Хәбәрлекле, ачыклаулы, аныклаулы мөнәсәбәт.

Сүзтезмә. Аның төрләре.

*Гади җөмлә*

Җөмләнең баш кисәкләре. Ия белән хәбәрнең төрләре. Ия белән хәбәрнең ярашуы.

Җөмләнең иярчен кисәкләре. Иярчен кисәкләрнең төрләре: аергыч, тәмамлык, хәл кисәкләр, аныклагыч. Туры һәм кыек тәмамлыклар. Хәл кисәкләрнең мәгънә ягыннан төрләре.

Бер составлы (атау, фигыль, сүз) һәм ике составлы җөмләләр.

Тулы һәм ким җөмләләр.

Әйтү максатыннан чыгып җөмлә төрләре: хикәя, сорау һәм боерык җөмләләр. Өндәү җөмлә.

Җөмләдә тиңдәш кисәкләр, алар янында тыныш билгеләре.

Аерымланган кисәкләр. Җөмләдә иярчен кисәкләрнең аерымлануы, алар янында тыныш билгеләре.

Җөмләдә сүз тәртибе: туры һәм кире (инверсия)

*Кушма җөмлә*

Кушма җөмлә турында гомуми төшенчә. Кушма җөмлә төрләре.

Тезмә кушма җөмлә. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмлә, алар янында тыныш билгеләре.

Иярченле кушма җөмләләр. Баш һәм иярчен җөмлә. Иярчен җөмләләрнең төзелеше һәм мәгънә ягыннан төрләре. Бәйләүче чараның төренә карап, татар телендә иярчен җөмләләр: аналитик һәм синтетик төзелешле иярчен җөмләләр.

Катлаулы төзелмәләр: күп иярченле кушма җөмләләр һәм аның төрләре, катнаш кушма җөмләләр.

Текст синтаксисы. Текстның бөтенлеге. Тезем.

Чит сөйләмле текст. Туры сөйләм. Кыек сөйләм. Уртак сөйләм.

## Күнегүләр. Биремнәр

**1. Бирелгән берәмлекләрне сүзтезмәләргә, тезмә сүзләргә һәм фразеологизмнарга аерып языгыз.**

Безнең йортыбыз, әнигә бүләк итү, озак көтү, кул чабу, кул бармау, алтын куллы, музыка тыңлау, сүз тыңлау, күргән саен сөенү, күз ачып йомганчы, ак кар, ял итү, җәен ял итү, тагын бару, әһәмият бирү, бүләк бирү, сүз бирү, мактап әйтү, инглизчә өйрәнү, барлыкка килү, боз тавы, сиңа таныш, биш чакрым юл, борынгы университет, Казан дәүләт университеты, искиткеч акыллы.

**2. Түбәндәге сүзтезмәләрне татар теленә тәрҗемә итегез.**

Ходить около леса, проходить мимо скамейки, говорить прямо, сказать правду, считаться с решением, добиваться согласия, учиться в школе, пытаться спорить, решать задачу, ставить под сиденье, кататься с горки, давать в займы, варить быстро, исчезнуть навсегда, кричать громко, ходить прямо, убирать постель, просматривать газеты, любить Родину, получать право, руководить больницой, называться лучшей, соломенная шляпа, каменный дом, один пуд пшеницы, город Елабуга, Воздушный флот, река Кама, гречневая каша, скользкая дорога, память отца, письмо от матери, сказанное слово, три девочки, летний отдых.

**3. Өзекне игътибар белән укыгыз. Җөмлә санын күрсәтегез. Баш кисәкләрне бергә язып алыгыз.**

Мин авылыбызның ... Рамазан чишмәсе буенда утырам. Ул авыл уртасындагы таулык куенынннан агып чыга да, ун адымлап йөгереп баргач, кечкенә елгачык эченә кереп югала.

Елганы чыпчыклар төркеме сырып алган. Алар чыркылдаша-чыркылдаша су чәчрәтеп уйныйлар. Томшыкларына тамчылар алып, күккә чөяләр дә, кабат кабып йотмакчы булып, югары күтәреләләр. Бераздан тагын әйләнеп кайталар!

Чыпчыклар уенына мавыгып, чишмә төбенә килеп төшкән сандугачны күрми дә калганмын икән. Бу ялгыз кош елга суына да, шунда чыркылдашып уйнаган чыпчыклар төркеменә дә исе китмичә, чишмәнең түренәрәк узды. Су буена килеп җиткәч, чишмәгә үрелер өчен, урын җайларга кереште. Аннары үзенең сусап-кибеп беткән томшыгын агымга төртте... (Г. Гыйльман).

**4. Тиешле урыннарда ия белән хәбәр арасына тыныш билгеләре куеп языгыз, кагыйдәләрен аңлатып, нәтиҗә ясагыз.**

1) Моң бүтән телләргә тәрҗемә ителми торган, ходай сулышы белән яратылган тылсымлы сүз (М. Галиев). 2) Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә, тик һәр йөрәк аны яңарта (Һ. Такташ). 3) Бөтен булган байлыгы урман, чишмәләр һәм кешеләр (М.Мәһдиев). 4) Балам балым, баламның баласы җаным

(Мәкаль). 5) Бу Гөлбану өчен икенче сынаш иде, ләкин сер бирмәде (Г. Ибраһимов). 6) Дүрт дүртең уналты. 6) Бу борынгыдан килгән сәнгатьнең язылмаган кануны (М. Галиев). 7) Дошманны җиңү өчен иң көчле корал аңа изгелек итү (Р. Фәхретдин).

**5. Җөмләләрне укыгыз. Җөмләнең кайсы кисәкләре (ия, хәбәр, аергыч, тәмамлык) тиңдәшләнеп килүен әйтегез. Тиңдәш кисәкләрнең үзара нинди чаралар белән бәйләнүләренә карап, тыныш билгеләренең куелышын аңлатыгыз.**

1) Биектә ак тун ябынган юан болытлар, уң якта яшеллеккә күмелгән урман, икенче якта Иделгә барып тоташкан иңкүлек җәйрәп ята (Т. Галиуллин). 2) Җил болытларны пыран-заран китерде, укмаштырды, таратты, талкыды (М. әмирханов). 3) Рәтен белеп малны чалу, кышка ит ризыгы, җәйгә казылык, каккан каз, җилдергән ит әзерли белү — татарның милли сыйфатларыннан берсе (М. Галиев). 4) Тышта салкын, караңгы (Г. Әпсәләмов). 5) Бүген көн аяз да, болытлы да (Г. Толымбай). *7)* Бу тойгыда җиңелчә генә моң, җиңелчә генә шатлык, нәрсәнедер җиңелчә генә сагыну, нәрсәнедер җиңелчә генә көтү, нәрсәгәдер җиңелчә генә куану, тагы әллә нәрсәләр бар иделәр (Ф. *Әмирхан).* 8) Безнең авылдан бер генә герой да, бер генә космонавт та, бер генә академик та чыкмаган. (М. Мәһдиев).

**6. Тиңдәш һәм тиңдәш булмаган аергычлар янында тиешле тыныш билгеләрен куеп языгыз.**

1) Төн гаҗәеп бер төн иде. Әйтерсең, бөтен җир өсте йомшак калын кара бәрхет белән капланган — шундый караңгы шундый җылы һәм шундый тын иде ул!.. (Ә. Еники).

2) Иртәнге иксез-чиксез зәңгәр күктә бүрек кадәр генә бер болыт йөзеп йөрде (Т. Әйди).

3) Көн кичкә авышып бара иде инде. Җылы нурлары белән аны озата килгән җемелдәшкән кар бөртекләре аша аның күзләренә өмет өстәп торган гайрәт биргән кояш та алсуланып баерга җыена иде (Р. Мөхәммәдиев).

4) Кызыл кофта кигән чәчләрен бөдрәләтеп тараган тутакай килеп керде (Г. Исхакый).

5) Тыгыз сары болытлы күк гөмбәзеннән кыр казлары китеп бара (М. Мәһдиев).

6) Ишек пары белән өйгә мамык шәл бөркәнгән кыска жакет кигән битенә мул итеп вазелин сөрткән кыйгач кашлы кыз килеп керде (М. Мәһдиев).

7) Җанны өшетә торган салкын коры кич килде (А. Гыйләҗев).

8) Нургали хыялы белән рәхәт дәрәҗәле көннәрне күз алдына китерде (М. Мәһдиев).

9) Җиргәнтауның Агыйделгә барып бәрелгән чите киртләчләнеп киртләчләнеп күтәрелгән биек-биек кызыл ярга әйләнеп китә (М. әмир).

10) Без тауга мендек тә аксыл нурга манчылып яткан тигез алан үзәгеннән сулга борылдык (Х. Сарьян).

**7. Аерымланган хәлләр янында кирәкле тыныш билгеләре куеп языгыз.**

1) Ә менә Клараның әтисе шул авылда туып-үскән булса да Каракошны сагынып бер дә телгә алмый иде. (Ә. Еники).

2) Сумкасын эчкә урнаштыргач малай үзе дә кереп ятты гәүдәсен тырышып-тырышып баштанаяк салам белән каплады. (Р. Низамиев).

3) Аны күрү белән егет чабаталарын тотып абзарга таба йөгерә дә тиз генә киенеп тә ала. (Әкият).

4) Ул арада диңгез ягыннан еракта гы ташкын тавышы сыман тонык бер шаулау ишетелде. Аның ни икәнен аннан соң тагын нәрсә булачагын абайлап өлгергәнче сулда, пычрак өстендә, озын булып сузылган буразна күренде. (Г. Бәширов)

5) Еракта, бик еракта, тын караңгылыкны нечкә генә нәфис кенә ярып экиятләрдә алтын кылыч селтәнгән шикелле итеп яшен яшьнәде (Г. Гобәй).

**8. Аерымланган аныклагычлар янында тиешле тыныш билгеләрен куеп языгыз.**

1) Аерата төпчек кызлары игезәкләр сылу булып үсте (А. Гыйләҗев).

2) Аның ягъни чын мәхәббәтнең асылда юклыгын без соңыннан белдек (Ә. Еники).

3) Яңа айның җидесендә изге бәйрәмнең соңгы көнендә Туман каган күк өйгә яңадан үзенең барлык туган-тумачасын, бәкләрне, агаларны җыйды (Н. Фәттах).

4) Сулда көнбатышта күңелсез караңгылык җәелеп ята, уңда көнчыгышта бераз гына ачыла башлаган күк чите һәм шундый ук караңгы бушлык барлыгы беленә иде (Н. Фәттах).

5) Бу бит бөтен группаның бөтен курсның хәтта факультетның уртак бәйрәме (Ф. Латыйфи).

**9. Аналитик кушма җөмләләрне укыгыз. Баш һәм иярчен җөмләләрне табып, үзара ничек бәйләнешкә керүләрен аңлатыгыз.**

1) Оясында ни күрсә, очканында шул булыр. (Мәкаль).

2) Ул вакыт агышын югалтты, әйтерсең лә аның үз вакыты. (Ф. Садриев).

3) Әйттем ич инде: гаделлек дигән кош артыннан мин җир читенә дә барырга риза. (М.Әмирханов).

4) Шунысы гаҗәп: тавышы бер дә картаймаган икән бит аның. (М. Гали).

5) Кемдер шулай кисәтә аны, хәтта ул кемдер аны өркетә, куркыта шикелле. (З. Хөснияр).

**10. Синтетик кушма җөмләләрдә тиешле тыныш билгеләрен куеп языгыз.**

1) Ходай кушылдырганны кеше аера алмас. (Мәкаль).

2) Башкалар ду килеп шаулашып шатланышып барганда мин моңаеп барам. (Г. Исхакый).

3) Әти-әнисе аның хәлен белеп торсын дип ул аларга атна саен хат язды (Ф. Хөсни).

4) Үзең тапмаган малның кадере булмас. (Мәкаль).

5) Казларны юып келәт киштәсенәменгереп элгәннән соң кызлар эре көмеш чәчәкләр төшерелгән яшел зәңгәр чиләкләр белән чишмәгә су алырга төшәләр. (Г. Бәширов).

## ЛИНГВИСТИК АНАЛИЗ ҮРНӘКЛӘРЕ

### СҮЗГӘ ФОНЕТИК АНАЛИЗ ЯСАУ ТӘРТИБЕ

1.Сүзне иҗекләргә таркатырга, басымын күрсәтергә.

2.Сүздә ничә аваз һәм хәреф барын билгеләргә.

3.Авазларны һәм хәрефләрне рәттән санап чыгарга.

4.Сузык авазларны рәттән санап чыгарга, әйтелешләрен билгеләп (калынмы-нечкәме, иренләшкәнме-иренләшмәгәнме), сүзнең сингарсонизм законына буйсыну-буйсынмавын ачыкларга.

5.Тартык авазларны рәттән санап чыгарга һәм әйтелешләрен билгеләргә (ясалу ысулы һәм урыны, яңгыраумы-саңгыраумы, ).

6.Аваз һәм хәрефнең бер-берсенә туры килмәгән очракларын билгеләргә һәм аңлатырга.

### СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕНӘ МОРФОЛОГИК АНАЛИЗ ЯСАУ ТӘРТИБЕ

**Исемгә анализ**

1.Ялгызлык яки уртаклык исем булуы.

2.Ясалышы.

3.Берлектә яки күплектә булуы.

4.Тартым белән төрләнгән булса, аның заты-саны.

5.Кайсы килештә булуы.

6.Кайсы сүзне ачыклавы (яки кайсы сүзгә иярүе) һәм нинди җөмлә кисәге булуы

**Сыйфатка анализ**

1. Сыйфатның ясалышы.
2. Дәрәҗәсе
3. Кайсы сүзне ачыклавы һәм нинди җөмлә кисәге булуы.

**Рәвешкә анализ**

1.Рәвешнең төркемчәсе.

2.Ясалышы.

3.Кайсы сүзне ачыклап килүе һәм нинди җөмлә кисәге булуы.

**Алмашлыкка анализ**

1.Алмашлыкныңтөркемчесе

2.Ясалышы.

3.Төрләнсә, нәрсә белән төрләнүе һәм нинди җөмлә кисәге булуы.

**Санга анализ**

1.Санның төркемчәсе.

2.Ясалышы.

3.Саналмышы булса, күрсәтергә, булмаса, ни өчен юк икәнен әйтергә.

4.Төрләнгән булса, нәрсә белән төрләнүен билгеләргә.

5.Туры яки күчерелмә мәгънәдә килүен күрсәтергә.

**Фигыльгә анализ**

1.Төркемчәсе.

2.Ясалышы.

3.Барлыктамы, юклыкта килүе.

4.Зат белән төрләнгән булса, заты, саны.

5.Заман белән төрләнгән булса, нинди заманда булуы.

6. Затланышсыз фигыль булса, кушымчасы; нәрсә белән төрләнүе; кайсы сүзгә ияреп килүе яки ачыклавы.

7. Нинди җөмлә кисәге булуы.

**Ярдәмлекләргә анализ**

1. Теркәгечнең төрен, кайсы сүз яки җөмләләрне бәйләвен әйтергә.

2. Кисәкчәнең кайсы сүзкә яки җөмләгә каравын, нинди мәгънә төсмере белдерүен әйтергә.

3, Бәйлекнең нинди килеш соравын һәм кайсы сүзләрне бәйләвен күрсәтергә.

## СИНТАКСИК АНАЛИЗ ҮРНӘКЛӘРЕ

### Сүзтезмәгә анализ ясау тәртибе

1.Сүзтезмәнең төзелеше: гади яки катлаулы булуы билгеләнә.

2.Ияртүче һәм ияртүче сүзләрнең нинди сүз төркеме белән белдерерүенә карап, сүзтезмәнең төре билгеләнә.

3.Иярүче сүзне ияртүчегә бәйләүче чара билгеләнә.

4.Иярүче сүз белән ияртүче арасындагы мәгънә мөнәсәбәте билгеләнә.

### Гади җөмләгә билгеләмә бирү тәртибе

1. Оештыручы үзәкнең санына карап, ике яки бер

составлы җөмләләр билгеләнә.

2. Мәгънә тулылыгы өчен кирәк булган кисәкнең булу-булмавына карап, җөмләнең тулы яки ким булуы күрсәтелә.

3. Әйтү максатына карап җөмлә төре әйтелә.

4. Чынбарлыктагы күренешләрне раслау яки кире кагуына карап, раслау яки инкяр җөмлә күрсәтелә.

5. Иярчен кисәкнең булу-булмавына карап, җыйнак яки җәенке җөмләләр билгеләнә.

6. Аерым җөмлә кисәкләренә таркала алу яки алмавына карап, грамматик таркала һәм таркалмый торган төрләр күрсәтелә.

7. Җөмләдә тиңдәш яки аерымланган кисәкләр күрсәтелә.

**Кушма җөмләгә синтаксик анализ тәртибе**

1.Хәбәрлекләрне табарга һәм алар арасындагы мөнәсәбәтне билгеләргә (җөмләләр арасында ияртүле бәйләнеш булса, баш җөмләне табарга).

2.Иярчен җөмләләрнең (яки тезүле бәйләнештә торган хәбәрлекләрнең) чиген билгеләргә һәм бәйләүче чараны күрсәтергә.

3.Җөмләнең схемасын ясарга.

4.Җөмләгә билгеләмә бирергә.

## Контроль тестлар

### Тест №1

(Фонетика)

**1. Тел гыйлеме — …**

1) телне, аның яшәү һәм үсеш закончалыкларын өйрәнә торган фән;
2) төрле яктан телнең сүзлек байлыгын өйрәнә торган фән;
3) сөйләм төзелешен өйрәнә торган фән.

**2. Татар теле — …**

1) тамыр тел;
2) полиситетик тел;
3) флектив тел;
4) агглютинатив тел.

**3. Аваз ул — …**

1) фонемаларның язуда белдерелүе;
2) тон һәм шау катнашында барлыкка килгән саңгырау берәмлек;
3) сөйләмнең таркалмый торган иң гади фонетик берәмлеге.

**4. Төрки телләрдә түбәндәге кушык авазларның кайсылары бар?**

1) дифтонглар;
2) трифтонглар;
3) ялган дифтонглар;
4) ялган трифтонглар.

**5. Сөйләм аппараты түбәндәге өлешләрдән тора:**

1) авыз куышлыгы, фаринкс, борын куышлыгы, бугаз куышлыгы;

**11. Татар телендәге [о] авазына кайсы характеристика туры килә?**

1) арткы рәт, урта күтәрелешле, иренләшкән сузык;
2) алгы рәт, урта күтәрелешле, иренләшкән сузык,
3) арткы рәт, урта күтәрелешле, иренләшмәгән сузык;
4) алгы рәт, урта күтәрелешле, иренләшмәгән сузык

**12. Яңгырау авазлардан гына торган төркемне табыгыз.**

1) б, ф, д, ш, к, ч
2) г, ж, җ, б, в
3) щ, х, т, с, ч, ц

13. **Тел алды авазын күрсәтегез**.

1) б
2) н
3) ң
4) х

**14. [w] авазына туры килгән характеристиканы күрсәтегез.**

1) ирен-ирен, өрелмәле, сонор, авыз авазы;
2) тел алды, ярым-йомык, сонор, авыз авазы;
3) ирен-теш, өрелмәле,

2) авыз куышлыгы, борын куышлыгы, үпкәләр, йөз;
3) йоткылык, иреннәр, тешләр, аңкау.

**6. Авазларны сузыклар һәм тартыкларга нинди күрсәткечләргә карап бүләләр?**
1) акустик;
2) артикуляцион;
3) акустик һәм артикуляцион.

**7. Авазларның позицион үзгәрешләренә түбәндәгеләр керә:**
1) эпентеза, ассимиляция, редукция, протеза, метатеза;
2) ассимиляция, диссимиляция; сингармонизм;
3) эпентеза, протеза, редукция.

8. **Элизия ул — …**
1) чит авазны кабул иткәндә, аны туган телдәге аваз белән алыштыру;
2) ике сүзнең беренчесе сузык авазга тәмамланып, икенчесе сузыкка башланып, бер басым астында барлыкка килә торган үзгәреш;
3) сүздәге авазларның урыннары алышыну.

**9. Сузык һәм тартыклар артикуляциясенең бер-берсенә җайлашуы ничек атала?**
1) ассимиляция;
2) аккомодация шаулы, яңгырау аваз;
4) ирен-ирен, йомык, сонор, борын авазы.

**15. Татар телендә йоткылык (фарингаль) авазы ничәү?**
1) 1
2) 2
3) 3
4) 4

**16. Татар теленә хас булмаган иҗек калыбын табыгыз.**
1) СТ;
2) ТСТ;
3) ТТС;
4) СТТ.

**17. *Әлбәттә* сүзендә басым кайсы иҗеккә төшә?**
1) 1;
2) 2;
3) 3.

**18. Кырмысканы кымрыкса (диал.) дип әйткәндә нинди аваз үзгәреше чагылыш таба?**
1) диэреза;
2) метатеза;
3) элизия;
4) субституция.

**19. *Табигать* сүзе нинди орфографик принцип буенча языла?**
1) фонетик;
2) морфологик;
3) тарихи-традицион;
4) график.

**20. Сүзгә дөрес**

3) сингармонизм;
4) диссимиляция.

**10. Татар телендә сузыкларны телнең горизонталь хәрәкәтенә карап төркемләгәндә нинди төркемнәр барлыкка килә?**

1) озын һәм кыска сузыклар;
2) иренләшкән һәм иренләшмәгән сүзыклар;
3) алгы һәм арткы рәт сузыклары;
4) югары, урта, түбән күтәрелешле сузыклар.

**транскрипция ясалган вариантны билгеләгез.**

1) [ķуәтлә];
2) [ķуwәтлә];
3) [ķүwәтлә];
4) [ķуатлә];

## Тест №2

(Лексикология)

**1.Этимология ул — …**

1) *Ялгызак* исемнәрне өйрәнә торган фән;
2) Сүзләрнең килеп чыгышын өйрәнә торган фән;
3) Сүзнең атау мәгънәсен, атама бирү закончалыкларын өйрәнә торган фән;
4) Телнең тотрыклы төзелмәләре җыелмасы.

**2. Күпер сүзе — …**

1) Бер мәгънәле сүз
2) Күп мәгънәле сүз

**3. *Имтиханда укытучы аны бөтенләй <u>коралсызландырды</u>* җөмләсендәге астына сызылган сүз нинди мәгънәдә кулланылган?**

1) Туры

**11. Килеп чыгышы ягыннан сүзнең кайсы телгә нисбәтле булуын күрсәтегез.**

*мунчала*

1) татар
2) монгол
3) гарәп
4) рус

**12. Килеп чыгышы ягыннан сүзнең кайсы телгә нисбәтле булуын күрсәтегез.**

*тәрбия*

1) татар
2) монгол
3) гарәп
4) рус

**13. Кулланылыш сферасыннан чыгып, лексеманың кайсы төркемгә**

2) Күчерелмә

**4. *Капкынга <u>кабу</u>* сүзтезмәсендәге астына сызылган сүз нинди мәгънәдә кулланылган?**

1) Туры
2) Күчерелмә

***5. Ярлы өйләр пычак кайрыйлар,*
*Ак сарайлар ашыгып хәйлә кора (Х.Т.)* шигъри юлларында күчерелмә мәгънәнең кайсы төре кулланылган?**

1) метафора
2) метонимия
3) синекдоха

**6. Омонимның төрен билгеләгез.**

***Бураннар басылды,***
***Басылды, күк ачылды, -***
***Бигрәк зәңгәр күк***
***Зәңгәр синең күзләр күк (Ш.Г.)***

1) Саф омоним
2) Омограф
3) Омофон
4) Омоформа

**7. Омонимның төрен билгеләгез.**

***Нишләтергә кәҗәбезне?***
***Аптыратты кәҗә безне (Р.М.)***

1) Саф омоним
2) Омограф
3) Омофон
4) Омоформа

**8. Парлы сүзләр нинди берәмлекләргә нигезләнеп барлыкка килгәннәр?**

*Чит-ят, бата-чума, әйләнә-*

**нисбәтле булуын билгеләгез.**

*Коптилка*

1) Гомумхалык лексикасы
2) Диалекталь сүз
3) Һөнәрчелек лексикасы
4) Жаргон сүз
5) Арго сүз

**14. Искергән сүзнең төрен билгеләгез.**

*Имана*

1) тарихи сүз
2) архаизм

**15. Фразеологизмны табыгыз.**

1) кулны сөртү
2) кул болгау
3) кулга кул тотыну
4) кул селтәү

16. **Фразеологизмга дөрес аңлатма бирегез**

*Арыслан йөрәкле булу*

1) батыр булу
2) куркак булу
3) хәйләкәр булу
4) ялагай булу

***17. <u>Котыбыз</u>*** *алынып торган идек (М.Ә)* җөмләсендәге астына сызылган сүзнең кайсы эмоциональ-стилистик катламга нисбәтлелеген күрсәтегез

1) көнкүреш сүзе
2) гади сөйләм сүзе
3) китап сүзе

18. **“Физика терминнары сүзлегеге” —**

1) энциклопедик сүзлек
2) филологик сүзлек

*тулгана*

1) Омоним
2) Антоним
3) Пароним
4) Синоним

**9. Антоним парларны табыгыз.**

1) Дискуссия — бәхәс
2) Кап — кап
3) Китү — калу
4) Әмер — фәрман

**10. Синонимик рәттәге доминанта сүзне табыгыз.**

1) Ризык
2) Нигъмәт
3) Ашамлык
**4)** Азык

19. **Сәйфуллин, Хәмзин, Мәхмүтовларның “Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге” — …**

1) энциклопедик сүзлек
2) филологик сүзлек

20.**Синонимик рәтне табыгыз.**

1) гомер, тормыш, яшәү, тере булу, мәгыйшәт
2) гомер, тормыш итү, тереклек, хәят, яши белү
3) гомер, тормыш, яшәеш, хәят, тереклек, мәгыйшәт

## Тест №3
(Морфология)

**1. Татар телендә ничә мөстәкыйль сүз төркеме бар?**

1) 5
2) 6
3) 7
4) 8

**2. Түбәндәге сүз нинди сүз ясалу ысулы белән ясалган?**

*Ирле — хатынлы*

1) фонетик
2) морфологик
3) морфологик — синтаксик
4) синтаксик

**3. Ялгызлык исемнәреннән генә торган төркемчәне табыгыз.**

**12. Җитмеш өч -…**

1) тамыр сан
2) ушма сан
3) тезмә сан
4) парлы сан

13. **Билгеләү алмашлыгын табыгыз**.

1) теге
2) һәммә
3) нидер
4) беркайчан да

**14. *<u>Тегеләр</u> ни өчендер килеп җитмәделәр* җөмләсендәге астына сызылган алмашлык-**

1) исем алмашлыгы
2) сыйфат алмашлыгы

1) кеше, Алсу, исем, дуслык,“Болгар ” радиосы.
2) Клуб, пароход, завод, конфет.
3) “ Химиклар сарае”, Суворов, КамАЗ, “Карлыгач”

**4. Татар телендә ничә килеш формасы бар?**

1) 6
2) 7
3) 8

**5. Астына сызылган исем кайсы заттагы тартым белән төрләнгән?**

<u>*Авылының*</u> *бормалы юлы.*

1) 1зат, берлектә
2) 2зат, берлектә
3) 3зат берлектә
4) тартым белән төрләнмәгән

**6. Җөмләдәге тартымлы исем кайсы килештә кулланылган.**

*Үги ана яфрагын язын җыярга кирәк.*

1) Баш
2) Иялек
3) Юнәлеш
4) Төшем
5) Чыгыш
6) Урын- вакыт

**7. Исемнең дөрес язылышын күрсәтегез.**

*Кызыл(...)түш*

1) ъ белән
2) ь белән
3) өстәмә билгесез, кушылып
4) өстәмә билгесез, аерым

**8. Яшькелт —...**

3) рәвеш алмашлыгы
4) сан алмашлыгы

**15. *Барча* —...**

1) тамыр сыйфат
2) тамыр алмашлык
3) ясалма сыйфат
4) ясалма алмашлык

**16. *Быел имтихан бирелмәде* җөмләсендәге фигыль -...**

1) затланышлы
2) затланышсыз

**17. *Килгәләгез* фигыле нинди юнәлештә?**

1) төп
2) төшем

**18. Сыйфат фигыль формасын табыгыз**

1) кайтмагач (килде)
2) язылмас (шигырьләр)
3) бармаска (булды)

**19. *Байтак*—**

1) билге рәвеше
2) хәл рәвеше

***20. Бәлки* —**

1) тезүче теркәгеч
2) ияртүче теркәгеч
3) бәйлек
4) кисәкчә

***21. Соң* —**

1) баш килешне сораучы бәйлек
2) юнәлеш килешне сораучы бәйлек
3) чыгыш килешне сораучы бәйлек

***22. Үк* —**

1) үзе бәйләнгән сүздән

1) асыл сыйфат
2) нисби сыйфат

**9. Сыйфатның дөрес язылышын табыгыз.**

***Тар(…)рак***

1) ы
2) ъ
3) өстәмә хәрефсез

**10. Кайсы раслау дөрес?**

1) сыйфатлар килеш белән төрләнәләр
2) сыйфатлар кайвакыт килеш белән төрләнәләр
3) сыйфатлар килеш белән төрләнмиләр

**11. 2/3 —бу…**

1) чама саны
2) бүлем саны
3) тәртип саны
4) микъдар саны

алда килә
2) үзе бәйләнгән сүздән соң килә
3) үзе бәйләнгән сүздән алда да, соң да килә

**23. *Ай – һай!* — нинди ымлык ?**

1) эмоцианаль
2) императив

**24. *Ялт!* бу — …**

1) ымлык
2) аваз ияртеме

**25. –дыр / -дер —**

1) кушымча
2) теркәгеч
3) кисәкчә

## Тест №4
(Синтаксис)

**1. Түбәндәге җөмләдә хәбәрлекле мөнәсәбәттәге ничә сүз бар?**

*Фердинант, галстугын төзәтә-төзәтә, музыка ишетелгән якка китте.*

1) 1
2) 2
3) 3

**2. Хәбәрлекле мөнәсәбәт булсын өчен, ничә мөстәкыйль сүз булырга тиеш?**

1) 1
2) 2

**13. *Өйдә дуслары гына утырып калган* җөмләсендәге ия — …**

1) гади ия
2) тезмә ия
3) кушма ия
4) иясе юк

14. ***Имтихан <u>сәгать</u> <u>тугызда</u> башланачак*** **җөмләсендәге астына сызылган сүз нинди җөмлә кисәге**?

1) аергыч
2) тәмамлык
3) вакыт хәле

3) 2дән ким түгел
4) ничә сүз булуы мөһим түгел

**3. Көн болытлы — ...**

1) исемле сыйфат сүзтезмә
2) сыйфатлы исем сүзтезмә
3) сүзтезмә түгел

**4. Сиңа хәтле белү — ...**

1) фигыльле бәйлек сүзтезмә
2) бәйлекле фигыль сүзтезмә
3) алмашлыклы бәйлек сүзтезмә
4) алмашлыклы фигыль сүзтезмә

**5. Эч пошыру — ...**

1) ирекле сүзтезмә
2) фразеологик сүзтезмә

**6.** *Җәен без имтиханнар тапшырачакбыз* **җөмләсендә ничә сүзтезмә бар?**

1) 4
2) 3
3) 2
4) 1

**7.** ***Бүген Алсуларга кирәсе түгел!*** **җөмләсе — ...**

1) раслау җөмлә
2) инкяр җөмлә

**8.** ***Мин йокларга телим!*** **—**

1) җыйнак җөмлә
2) җәенке җөмлә

**9.** ***Җыелышта әйтелгәннәр дөрес булып чыкты*** **—**

4) урын хәле
5) күләм хәле

**15. Җөмләнең төрен билгеләгез.**

***Кырга чыга һәм күзе караган якка таба акрын гына китеп бара.***

1) гади җөмлә
2) тезмә кушма җөмлә
3) иярченле кушма җөмлә

16. **Иярченле кушма җөмләдәге баш җөмлә белән иярчен җөмләләрне бәйләүче чараларны күрсәтегез.**

*Тагын шунысы кызык: директорны күрәсе килү бишләтә, унлата көчәеп китте.*

1) күтәрү паузасы
2) мөнәсәбәтле сүз
3) янәшә тору
4) кушымча

**17. Иярчен җөмләнең төрен билгеләгез.**

*Син аңла: мондый әсәр язарга ярамый.*

1) синтетик
2) аналитик

**18. Иярчен җөмләнең мәгънә ягыннан төрен билгеләгез.**

*Мин эш юктан тирә-юньгә күз салдым.*

1) аналитик иярчен сәбәп җөмлә
2) синтетик иярчен сәбәп җөмлә
3) аналитик иярчен тәмамлык җөмлә

1) бер составлы
2) ике составлы җөмлә

***10.*** **Җөмләгә кайсы характеристика туры килә?**

*Аңа әле өйдә дә шактый эләкте.*

1) гади, тойгылы, раслау, җәенке, бер составлы, тулы
2) гади, хикәя, инкяр, җыйнак, ике составлы, тулы
3) гади, хикәя, рслау, җәенке, бер составлы, ким

**11.** ***Аның сүзләре эчне пошыра башлаган иде*** **җөмләсендәге хәбәр …**

1) гади
2) кушма
3) тезмә

**12.** ***<u>Тел белән</u> кызыксынуларым күптәннән башланды*** **җөмләсендәге астына сызылган сүз нинди җөмлә кисәге?**

1) аергыч
2) тәмамлык
3) хәл
4) аныклагыч

4) синтетик иярчен аергыч җөмлә

**19. Катлаулы кушма җөмләнең төрен билгеләгез.**

*Гөлзифа Давытка таба елыша төште, яныңда сөекле кешең барда туңып утырырга әле монда!*

1) күп тезмәле
2) күп иярченле
3) катнаш

**20. Җөмләгә туры килгән схеманы табыгыз.**

*Беренче кат күрүләремнән*
*Кырык биш ел үткәч кимендә,*
*Кем уйлаган, Галимҗан абый,*
*Үксермен дип изге өеңдә...*
*(Х.Т.)*

1) [ 2 ] ←( 3 ) ← ( 1 )
2) [ 1] = [ 2] =[ 3]
3) [ 1 ] ←( 2)
4) [ 3] ←( 2) ←( 1)

## Зачет өчен якынча сораулык

1. Татарларда язу тарихы.
2. Хәзерге татар әдәби теленең барлыкка килү тарихы.
3. Орфоэпия фәне. Аны өйрәнүнең әһәмияте.
4. Татар телендә басым.
5. Орфоэпиянең кыен очраклары.
6. Орфография фәне. Аны өйрәнүнең әһәмияте.
7. Орфографик принциплар.
8. Сүзләрне морфологик принципка нигезләнеп язу.
9. Сүзләрне тарихи-традицион принципка нигезләнеп язу.
10. Татар телендә гарәп-фарсы алынмалары.
11. Исем. Исемнең килеш белән төрләнеше.
12. Исемдә сан категориясе.
13. Сыйфат. Сыйфат дәрәҗәләре.
14. Сан. Сан төркемчәләре.
15. Саннарның төзелеше һәм дөрес язылышы.
16. Алмашлык. Алмашлык төркемчәләре.
17. Рәвеш. Рәвеш төркемчәләре.
18. Фигыль.
19. Фигыль төркемчәләре.
20. Затланышлы фигыльләр.
21. Затланышсыз фигыльләр.
22. Билгеле киләчәк заман хикәя фигыльнең дөрес язылышы.
23. Аваз ияртемнәре.
24. Кисәкчәләр.
25. Бәйлекләр.
26. Теркәгечләр.
27. Ымлыклар.
28. Хәбәрлек һәм модаль сүзләр.
29. Татар телендә рус-европа алынмалары.
30. *-да/-дә; -та/-тә* кушымчаларының, *да, дә, та, тә* кисәкчәләренең һәм теркәгечләренең дөрес язылышы.
31. Татар телендә *е, ё, ю, я* хәрефләренең дөрес язылышы.
32. Татар телендә *е, ё, ю, я* хәрефләре белдергән авазлар. Бу хәрефләрнең сүз төрләнешендәге роле
33. [w] авазының язуда бирелеше.
34. *ь* һәм *ъ* билгеләренең дөрес язылышы.

35. *ь* һәм *ъ* аеру билгеләренең дөрес язылышы.
36. “Һәмзә” авазының язуда бирелеше.
37. *Е, й, җ, ю, я* хәрефләрен дөрес язу мәсьәләләре.
38. *О,ө, ы, э* хәрефләренең дөрес язылышы.
39. Баш хәрефне дөрес язу очраклары.
40. *Й* хәрефенә беткән сүзләргә кушымчалар ялгану очраклары.
41. Сүзләрне юлдан юлга күчерү.
42. Кушма сүзләр орфографиясе.
43. Парлы сүзләр орфографиясе.
44. Кыскартылма сүзләр орфографиясе.
45. Тезмә сүзләр орфографиясе.
46. Ялгызлык исемнәрнең дөрес язылышы.
47. Сүз ясалышы ысуллары.
48. Сүз төзелеше.
49. Аерымланган хәлләр янында тыныш билгеләре.
50. Ия белән хәбәр арасында сызык куелу очраклары.
51. Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре.
52. Кереш сүзләр янында тыныш билгеләре.
53. Эндәш сүзләр янында тыныш билгеләре.
54. Аныклагычлар янында тыныш билгеләре.
55. Әйтү максатына бәйле тыныш билгеләре.
56. Өтер куелу очраклары.
57. Сызык куелу очраклары.
58. Ике нокта куелу очраклары.
59. Нокта куелу очраклары.
60. Инфинитивның дөрес язылышы.
61. Нокталы өтер куелу очраклары.
62. Ике тыныш билгесе янщшщ куелу очраклары.
63. Җәяләр куелу очраклары.
64. Туры сөйләмдә тыныш билгеләре.
65. Иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре.
66. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше.
67. Сүзтезмә.
68. Җөмләләрне төркемләү принциплары.

## Төп әдәбият исемлеге

1. Татар телендә тыныш билгеләре: белешмә / Төз.: Сафиуллина Ф.С., Ибраһимов С.М., Вафина Э.Х. - Казан: Мәгариф, 1995. - 47 б. - Кол-во: 5 шт.
2. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Күнегүләр җыентыгы. - Казан: Мәгариф, 2002. - 344 б. - Кол-во: 100 шт.
3. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле.- 3-нче басма.-Казан: Мәгариф, 2006. - 406 б. - Кол-во: 100 шт.
4. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле:күнегүләр: Югары һәм урта уку йортлары өчен.-2-нче басма, тулыл..-Казан: Мәгариф, 2002.-342 б. - Кол-во: 100 шт.
5. Татар грамматикасы. Фонетика. 3 томда. Т.1. – Мәскәү: Инсан, Казан: Фикер, 1998.- 510 б. - Кол-во: 5 шт.
6. Татар грамматикасы. Млрфология. 3 томда. Т.2. – Мәскәү: Инсан, Казан: Фикер, 1998.- 447 б. - Кол-во: 8 шт.
7. Татар грамматикасы. Синтаксис. 3 томда. Т.3. – Мәскәү: Инсан, Казан: Фикер, 1998.- 510 б. - Кол-во: 5 шт.

## Өстәмә әдәбият исемлеге

*а) татар телендә:*

8. Әдәбият белеме сүзлеге / Төз.-ред.: А.Х. Әхмәдуллин. – Казан: Татар кит.нәшр., 1990. – 238 б.
9. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.
10. Бәширов Г. Тел турында кайбер фикерләр / Г. Бәширов // Бүген дә, иртәгә дә. – Казан: Татар кит.нәшр., 1974. – Б. 227-236.
11. Бәширова И.Б. Сүз белән сурәт ясау (әдәбият укытучысына ярдәмгә) / И.Б. Бәширова. – Казан: Татар кит.нәшр., 1974. – 176 б.
12. Бәширова И.Б. Сәнгатьле чәчмә әсәрләр геле: Татар прозасында хикәяләү стильләренең үсеше һәм аның әсәр теленә тәэсире (VIII – X класслар өчен әдәбияттан кулланма) / И.Б. Бәширова. – Казан: Татар кит.нәшр., – 1979. – 96 б.
13. Газизова Г.Р. Фатих Кәриминең проза әсәрләрендә лексик-семантик һәм стилистик үзенчәлекләр: Филология

фәннәре канд. ... дис. / Г.Р. Газизова. – Казан: КДУ нәшр., 2002. – 202 б.
14. Галләмов Ф. Бәйләүче чара буларак кабатлаулар / Ф. Галләмов // Мәгариф. – 2001. – № 5. – Б. 100-101.
15. Гарифуллин В.З. Газета текстының төзелеше / В.З. Гарифуллин. –Казан: Татар кит.нәшр., 1995. – 104 б.
16. Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле һәм пунктуациясе / М.З. Зәкиев. – Казан: Татар кит.нәшр., 1984. – 163 б.
17. Ибраһимов С.М. Татар телендә синтаксик синонимнар / С.М. Ибраһимов. – Казан: КДУ нәшр., 1976. – 167 б.
18. Ибраһимов С.М. Синтаксик стилистика / С.М. Ибраһимов. – Казан: КДУ нәшр., 1990. – 156 б.
19. Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы / Х.Р.Курбатов. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.
20. Курбатов Х.Р. Татар теленең синтаксис һәм стилистика мәсьәләләре / Х.Р. Курбатов. – Казан: Татар кит. нәшр., 1956. – 176 б.
21. Курбатов Х.Р. Хәзерге татар әдәби телендә туры, кыек һәм уртак сөйләмнәр: Филология фән. канд... дис. / Х.Р. Курбатов. – Казан, 1953. – 341 б.
22. Курбатов Х.Р. Хәзерге татар теленең стилистик системасы / Х.Р. Курбатов. – Казан: Татар кит. нәшр., 1971. – 248 б.
23. Низамов И.М. Уем тел очында... (Сөйләм һәм массакүләм аралашу) // Татар сөйләменең нигезләре. Беренче кисәк / И.М. Низамов. – Казан: Татар кит. нәшр., 1995. – 287 б.
24. Поварисов С.Ш. Мәктәптә әдәби әсәрләрнең телен өйрәнү / С.Ш. Поварисов. – Казан: Татар кит. нәшр., 1978. – 217 б.
25. Сафиуллина Ф.С. Сүз иясе беләи йөри / Ф.С. Сафиуллина. — Казан: Татар кит. нәшр., 1985. – 136 б.
26. Сафиуллина Ф.С. Тел дигән дәрья бар... / Ф.С. Сафиуллина. — Казан: Татар кит. нәшр., 1979. – 136 б.
27. Татар грамматикасы. – Том III. – М.: “ИНСАН”, Казан: “ФИКЕР”, 1999. – 512 б.

28. Хаков В.Х. Мәктәптә татар язучысының тел үзенчәлекләрен өйрәнү / В.Х. Хаков. – Казан: Татар кит.нәшр., 1984. – 145 б.
29. Хаков В.Х. Татар әдәби стиле (стилистика) / В.Х. Хаков. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1999. – 304 б.
30. Хаков В.Х. Татар милли әдәби теле һәм аның стильләре үсеше. XIX йөзнең икенче яртысы – XX йөз башы: Филология фән. докт. ... дис. / В.Х. Хаков. – Алма-Ата, 1971. – 176 б.
31. Хаков В.Х. Татар теле стилистикасына кереш / В.Х. Хаков. – Казан: Татар кит. нәшр., 1963. – 164 б.
32. Хаков В.Х. Тел – тарих көзгесе (Татар әдәби теленең үсеш тарихыннан) / В.Х. Хаков. – Казан: Татар кит. нәшр., 2003. – 295 б.
33. Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе / Ф.М. Хатипов. – Казан: Раннур, 2002. – 352 б.
34. Шакирова Г.М. Гаяз Исхакый әсәрләренең текст буларак оешуы: фил. ф. канд. ... диссертациясе / Г.М. Шакирова. – Казан, 2009. – 197 б.
35. Шаехов М.Р. Структура текста современных татарских рассказов: автореферат дис. ... канд. филол. наук: 10.02.02.- Казань, 2012.- 22 с.

*ә) рус телендә:*

1. Арутюнова Н.Д. Человеческий фактор в языке. Коммуникация, модальность, дейксис / Н.Д. Арутюнова. — М.: Наука, 1992. – 281 с.
2. Брудный А.А. Психологическая герменевтика / А.А. Брудный. – М.: Лабиринт, 1998. –336 с.
3. Валгина Н.С. Теория текста: учебное пособие / Н.С. Валгина. – М.: Логос, 2004. – 280 с.
4. Виноградов В.В. О теории художественной речи / В.В. Виноградов. – М.: «Высшая школа». 1971. – 181 с.
5. Виноградов В.В. Стилистика. Теория поэтической речи. Поэтика / В.В. Виноградов. – М.: Изд-во АН СССР. – 1973. – 255 с.
6. Винокурова И.Ж. Языковой механизм связности зачина и концовки в тексте короткого рассказа / И.Ж. Винокурова. // Вестник ЯГУ. Том 4, № 1. – Якутск: Изд-во ЯГУ, 2007. – С. 79-85.

7. Ворожбитова А.А. Теория текста: Антропоцентрическое направление: учеб. пособие / А.А. Ворожбитова. – М.: Высшая школа, 2005. – 367 с.
8. Закиев М.З. Синтаксический строй татарского языка / М.З. Закиев. – Казань: Изд-во КГУ, 1963. – 464 с.
9. Ибатуллина Д.Э. Поэтика прозы Амирхана Еники: автореферат дис. ... канд. филол. наук / Д.Э. Ибатуллина. – Казань: Б.И., 1993. – 21 с.
10. Иванчикова Е.А. Синтаксис художественной прозы Достоевского / Е.А. Иванчикова. – М.: Наука, 1980. – 287 с.
11. Кузьмина Х.Х. Принципы анализа языка художественных произведений в татарском языкознании / Х.Х. Кузьмина // Ученые записки КГУ. Том 150, кн. 8. – К.: Изд-во КГУ, 2008. – С. 116-122.
12. Купина Н.А. Филологический анализ художественного текста: Практикум / Н.А.Купина, Н.А.Николина. – М.: Флинта: Наука.–2003.– 408 с.
13. Лингвистика и филологическая герменевтика: Сборник научных трудов. – Тверь: Изд-во ТвГУ, 2003. – 134 с.
14. Литературный текст: проблемы и методы исследования // Тверский государственный университет: Отв. ред. И.В.Фоменко. – Тверь: Изд-во ТвГУ, 1994. – 178 с.
15. Москальская О.И. Грамматика текста / О.И. Москальская. – М.: Выс. школа, 1981. –183 с.
16. Одинцов В.В. Стилистика текста / В.В. Одинцов. – М.: Наука. – 1980. – 264 с.
17. Почепцов Г.Г. Прагматика текста / Г.Г. Почепцов // Коммуникативно-прагматические и семантические функции речевых единиц: Межвуз. тематич. сборник. – Калинин: КГУ, 1980. – С. 5-10.
18. Сафиуллина Ф.С. Порядок слов в современном татарском литературном языке: автореферат дис. ... канд. филол. наук / Ф.С. Сафиуллина. – К.: Изд-во КГУ, 1965. – 21 с.
19. Сафиуллина Ф.С. Порядок слов в современном татарском литературном языке: диссертация ... канд. филол. наук / Ф.С. Сафиуллина. – К.: Изд-во КГУ, 1965. – 305 с.
20. Сафиуллина Ф.С. Развитие синтаксического строя татарского литературного языка (XX век): дисс. в виде науч.

докл... д-ра филол. наук. / Ф.С. Сафиуллина. – К.: Изд-во КГУ, 2000. – 116 с.
21. Сафиуллина Ф.С. Развитие синтаксического строя татарского языка в советский период: (Простое предложение) / Ф.С. Сафиуллина. – Казань: Изд-во КГУ, 1990. – 228 с.
22. Сафиуллина Ф.С. Синтаксис татарской разговорной речи / Ф.С. Сафиуллина. – Казань: Изд-во КГУ, 1978. – 253 с.
23. Серебрякова С.Г. Функционально-стилистические особенности прозы Р.Даля: автореферат дис. ... канд. филол. наук / С.Г. Серебрякова. – СПб: СПбГУ, 2007. – 18 с.
24. Солганик Г.Я. Стилистика текста / Г.Я. Солганик. — М.: Флинта, Наука, 1997. – 256 с.
25. Теория текста: учеб. пособие / Ю.Н. Земская, И.Ю. Качесова, Л.М. Комиссарова, Н.В. Панченко, А.А Чувакин. – М.:Флинта, Наука.– 2010. – 132 с.
26. Тер-Минасова С.Г. Язык и межкультурная коммуникация / С.Г. Тер-Минасова. – М.: Слово, 2000. – 262 с.
27. Художественный текст в современной лингвистической парадигме: учебно-методич. пособие для вузов. – Воронеж: Изд-во унив-та, 2007. – 50 с.
28. Чернявская В.Е. Лингвистика текста: поликодовость, интертекстуальность, интердискурсивность. Учеб.пособие / В.Е.Чернявская – М.: Книжный дом «ЛИБРОКОМ», 2009. – 248 с.